МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ___172/о_______

П Р И К А З    Б О Е Р Ы К

«__29___»______10________20_21_

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2021-2022 елларга «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең инвестиция программасын раслау турында» 2020 елның 29 октябрендәге 174/о номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм эшчәнлек башкару программаларын эшләү, раслау һәм төзәтү тәртибен, шул исәптән каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, зарарсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең план һәм фактагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм эшәнлек башкару программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә **боерык бирәм**:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2021-2022 елларга «Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең инвестиция программасын раслау турында» 2020 елның 29 октябрендәге 174/о номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «2021-2022 елларга» сүзләрен «2021 елга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2021-2022 елларга» сүзләрен «2021 елга» сүзләренә алмаштырырга;

«Гринта» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең күрсәтелгән боерык белән расланган инвестиция программасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

**Министр** **М.М.Айзатуллин**